وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№5 (148). 3 август 2012 / 15-рамазан-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Аксакал Гыйльмулла хәзрәт: "Безгә пикет-митинглар артыннан йөрергә кирәкми!" ▷2◁



РИУ ректоры: "Татарстанда яшерен радикаль агымнар юк" ▷3◁



Йөрәк авырулы кешеләргә ураза тотарга ярый ▷4◁

## ИФТАРЛАР

**ЗӘЙ РАЙОНЫ**

Зәй районы имам-мөхтәсибе Сәгыйть хәзрәт Камалов районның үзәк мәчетендә көн саен ифтар мәҗлесләре оештырылуын хәбәр итте: “Ифтар ашларына 25-30 кеше йөри, мәчеткә йөрүче мөселман кардәшләребезнең ярдәме белән уздырабыз. Төркиядән кайткан Коръән-хафиз Исмәгыйль Акбулут мәчеткә йөрүчеләр белән бергә тәравих намазлары укый, Коръән дәресләре бирә. Икмәк кабул итү бистәсендә яңа мәчет төзелеп килә, гает бәйрәменә кадәр өлгертергә исәбебез бар”.

**САБА РАЙОНЫ**

Ифтар мәҗлесләренең күбесен халык үзе үткәрә икән. Быел Төркиядән Дурмуш Ядгин исемле Коръән-хафиз кайткан, ул үз чиратында мәхәллә халкы өчен Коръән дәресләре үткәрә, тәравих намазларын укыта, дип хәбәр итте район имам-мөхтәсибе Айнур хәзрәт Әхмәтов.

**ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ**

Түбән Кама шәһәренең Җәмигъ мәчетендә көн саен 600 мөселман кардәшебез өчен ифтар мәҗлесләре оештырыла. Хатын-кызлар – мәчет эчендә, ир-атлар исә ишегалдындагы чатырда авыз ача. Ифтар ашларына теләгән һәркем килә ала. Быел шунысы үзенчәлекле: бер көнне укытучыларның, икенче көнне табибларның да бергә җыелуын күрергә мөмкин.

**ЧИРМЕШӘН РАЙОНЫ**

27 июль көнне Чирмешән авылы мәчетендә ифтар мәҗлесе уздырылган. Әлеге ифтар ашы мәчеткә актив йөрүчеләр һәм шәкертләр тарафыннан оештырылган. Мәҗлес барышында Коръән укылган, вәгазь-нәсыйхәтләр сөйләнгән. Барлыгы 100 ләп мөселман катнашты, дип хәбәр иттеләр мөхтәсибәттән.

**КАЙБЫЧ РАЙОНЫ**

27 июль көнне Олы Кайбыч авылы мәчетендә ир-атлар өчен ифтар мәҗлесе оештырылган. Ифтарның барлык чыгымнарын да Олы Кайбыч авылы эшмәкәре Гарәфетдинов Рамил Зөфәр улы күтәргән. Ифтар барышында Төркиянең Карс шәһәреннән килгән Эрдиндж Даштан әфәнде Коръән укыган, ураза хакында вәгазләр сөйләгән һәм тәравих намазын укыткан. Бу чарада кырыктан артык кеше катнашкан.

3 август көнне бирedә хатын-кызлар өчен ифтар мәҗлесе оештырырга уйлыйлар. Ә менә 15 август көнне Кайбыч районы хакимияте дә Олы Кайбыч авылының банкет залында ураза тотучы мөселманнарны ифтарга җыярга ниятли.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

## "Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында"гы ТР Законына әзерләнгән үзгәрешләр имамнар һәм мөхтәсибләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салырга ярдәм итәчәк

**"Республиканың мөселман дине вәкилләренә булган һөҗүм - хокук саклау органнарына да, хакимияткә дә чакыру. Шул ук вакытта ул республикада тотрыклы вазгыятьне, этноконфессиональ өлкәдә ышаныч һәм килешүгә корылган мохитне какшатырга омтылучы көчләрнең булуы турындагы сигнал да". 1 август көнне ТР Дәүләт Советы Президиумы утырышында парламент рәисе Фәрит Мөхәммәтшин шулай дип белдерде. Анда әлеге вакыйгаларга бәйле рәвештә, 3 августта парламентның чираттан тыш утырышын уздыру хакында карарга килende. "Тагын бер кат мөселман өммәтенең, республикадагы башка конфессияләрнең хәлен, конфессияләр арасындагы татулыкны тагын да ныгыту чараларын карарга кирәк". Парламент рәисе чираттан тыш утырышка җыелуның максатын шулай аңлатты.**

Фәрит Мөхәммәтшин хокук саклау органнарының җинаятьчеләрне табу һәм җәзага тарту буенча ышанычлы чаралар күрүен, шул ук вакытта бу эштә гамәлдәге законнарны, гражданнарның процессуаль нормалар һәм хокукларын тайпылышсыз үтәү кирәклеген искәртте. "Безнең бурыч - хәлләрнең торышын игътибар белән анализлап, экстремизм, аның төрле чагылышларын кисәтү буенча тиешле хокукый актлар кабул итү. Татарстанда дини берләшмәләр һәм конфессиональ берләшмәләрнең саны шактый. Ләкин моңарчы беркайчан да эшнең көч куллануга барып җиткәне булмады. Безнең сәяси-иҗтимагый культура өчен бу әйберләр хас түгел. Шуңа күрә булган әлеге процессларга юридик-хокукый бәя бирү белән генә чикләнмичә, әхлакый, сәяси бәяләмә бирү дә кирәк", - дигән фикердә ТР Дәүләт Советы рәисе.

Аның белдерүенчә, ил төбәкләрендә 1980 нче еллар азагында милли, дини үзаңның көчле күтәрелеше гыйбадәт йортлары санының артуына китерде. Ләкин аларның гыйлемле кадрлар белән тәэмин ителеше, эчтәлек-методологик ягы аксый. "Республикадагы, башка төбәкләрдәге мөселман өммәтенә килгәндә, Россия мөселманнары өчен хас традицион исламны алга сөргән, тиешле әзерлекле дин әһелләренең, имамнарның җитмәве күзәтелә. Бу хәлдән билгеле бер көчләр, шул исәптән чит илләрдәге көчләр дә файдалана. Безнең өчен чит булган принципларны алга сөргән дәгъватчылар барлыкка килде, аларның яшьләр арасында актив эш алып баруы аеруча куркыныч", - дип ассызыклый Фәрит Мөхәммәтшин.

Аның белдерүенчә, ТР Дәүләт Советының моңа мөнәсәбәтле рәсми позициясен эшләгәндә, конституцион строй нигезләрен, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен, аларның иминлеген саклау ихтыяҗыннан чыгып эш итәргә кирәк. "Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында"гы республика законына үзгәрешләр кертү турындагы канун проекты һәм Татарстанда дини экстремизмга каршы тору, профилактика чаралары турындагы ТР Дәүләт Советы карары проекты шуны күздә тотып әзерләнгән дә. 3 августта парламентның чираттан тыш утырышы көн тәртибенә чыгарылачак әлеге документлар республикада урнашкан толерантлык традицияләрен саклауга, конфессияләр эчендәге һәм конфессияара татулыкны ныгытуга хезмәт итәргә тиеш. Аларны әзерләүдә ТР Президенты Аппараты, Хөкүмәт, ТР Прокуратурасы белгечләре, республикадагы традицион конфессияләр вәкилләре катнашкан.

"Безнең бу күренешләргә реакция әлеге чаралар белән генә чикләнеп калмаячак. Бу юнәлештә масштаблы, комплекслы һәм күп аспектлы характерда эш алып барылырга тиеш. Административ, көч ысулларын кулланып кына бу проблемаларны чишеп булмаячак. Федераль, төбәк, муниципаль дәрәҗәләрдә мәгълүмат, милли, мәгариф сәясәте алып барылырга тиеш", - дип ассызыклады парламент рәисе.

Президиум утырышы соңында Фәрит Мөхәммәтшин журналистлар белән булган әңгәмәсендә "Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында"гы республика законына әзерләнгән кайбер үзгәрешләргә ачыклык кертеп узды.

Аның аңлатуынча, әлеге закон республикада дини оешмалар белән дәүләт хакимияте арасындагы мөнәсәбәтләрне көйли. Үзгәрешләр ярдәмендә гамәлдәге канунның кайбер өлешләренә ачыклык кертеләчәк. Аерым алганда, үзгәрешләр имамнар һәм мөхтәсибләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрен документлар ярдәмендә җайга салырга ярдәм итәчәк. "Аларны да социаль яктан якларга кирәк, эшкә урнашканда социаль гарантияләр булдырылырга тиеш. Бүген әле алар белән мәчетләр, мөхтәсибәтләр арасында документлар нигезендә расланган хезмәт мөнәсәбәтләре корылмаган", - дип искәртте Ф.Мөхәммәтшин. Аның белдерүенчә, канундагы башка кайбер маддәләрнең аерым пунктларына кертелә торган үзгәрешләр Диния нәзарәтенә үз устав документлары һәм гамәлдәге социаль гарантияләр кысаларында кадрлар тупларга, аларны укытырга, алар белән дәгъват эшенә керешү турында килешүләр төзергә ярдәм итәчәк. Фәрит Мөхәммәтшин ассызыклаганча, канунга әзерләнгән үзгәрешләр чит илләрдә дин гыйлемен үзләштереп кайткан дин әһелләренең хезмәт хокукларын чикләүне күздә тотмый. "Әгәр аларның чит илдә дини гыйлем алып кайтуы турындагы дипломы Россиядә сертификацияләнә икән, аларга эшчәнлек алып баруга тыю юк", - диде ул.

**"Татар-информ" мәгълүмат агентлыгы**

## РАМАЗАН БҮЛӘКЛӘРЕ



**Әлхәмдүлилләһи раббил галәмиин. Вәл гакыйбәтүлил мүттәкыйн. Вәссаләтү вәссәләәмү галә Мүхәммәдин вәгалә әлиһи вә сахбиһи әҗмәгыйн. Барлык мактауларыбыз галәмнәрнең Раббысы булган Аллаһы Тәгаләгә булса иде. Рәсүлебезнең (сгв) рух-шәрифенә дип атап әйткән салават-шәрифләребез булса иде. Һәм дә иң беренче Адәмнән (гс) алып, бүгенге көнгә хәтле килеп киткән барлык мөэмин вә мөэминәләрнең дә рух-шәрифләренә дип кылган изге догаларыбыз булса иде.**

Рамазан ае ул - бигрәк тә тәравих намазлары белән, Аллаһыбызның Изге Китабын укып, гыйбрәтләнүләр белән, иманыбызның көчен тагын да арттыру ягыннан караганда, башкалардан аерылып тора. Адәм балаларының көне буе ураза тотып аруларына карамастан, йөгерә-йөгерә, мәчетләргә тәравих намазларын укырга ашыгып килүләре, төрле файдалы вәгазьләр тыңлап, иманнарын куәтләп, озак вакыт намазларда торулары бик тә кадерле гамәлдер. Мөселманнар, ничек кенә арысалар да, тәравих намазларын калдырмыйлар, даими йөриләр, чөнки, аруга караганда, Аллаһның рәхмәте күпкә кадерлерәк. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйтә: "Кем дә кем намазга имам белән кереп, имам белән чыгып китә икән, төне буе бертуктаусыз намаз укыган кадәр әҗер-савап алыр". Габдрахман ибне Гауф рәсүлебездән бу хәдисне риваять итә: "Рамазан аеның уразасын Раббыбыз фарыз итте, тәравих намазларын мин сөннәт иттем. Кем дә кем Рамазан аенда, көндезләрен ураза тотып, ә кичләрен тәравих намазлары өстендә үткәрсә, әнисеннән яңа туган сабый бала шикелле бу айдан гөнаһларсыз чыгар".

Әбу Сөләйман Әддәрани: "Әгәр бу караңгы төннәрнең намазлары булмаган булса, мин бу дөньяны бөтенләй сөймәс идем", - ди. Пәйгамбәребез (сгв) әйтә: "Фарыз намазлардан соң иң хәерле намаз - ул төнге намаз". Гайшә анабыз болай дигән: "Пәйгамбәребез төнге намазларда торганда, аның бөтен аяк балтырлары шешә иде. Мин аңар-

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# РАМАЗАН БҮЛӘКЛӘРЕ

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

дан: "Әй Аллаһның рәсүле, Раббыбыз синең иң әүвәлге вә иң ахыргы гөнаһларыңны гафу итте, ник син үзеңне шулай газаплыйсың? - дип сорагач: - Менә шуның аркасында мин рәхмәтсез булып калыйммы инде?!" - дип җавап бирә иде", ди.

"Рамазан ае кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган ап-ачык дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр. Шуңа күрә, шушы айга килеп ирешкәннәр ураза тотсын..." ("Бәкара (Сыер)" сүрәсе, 185 нче аять). Ул кешеләргә туры юлны күрсәтә торган маяк вә яхшыны яманнан аера белергә өйрәтә торган ачкыч булып тора. Кем дә кем бу айны күрсә, ураза тотсын. Без, Коръән өммәте, иң хәерле өммәт булдык. Без, әлеге Китапны укып, аның мәгънәләренә төшенеп, аңа туры килгән гамәлләр кылып яшәргә тиеш булабыз. Пәйгамбәребез (сгв) үзенең бер хәдис-шәрифендә әйтә: "Әссыяму вәл Куръәну йәшфәгани лил габди яумәл Кыямәти". ("Дөрестән дә, ураза белән Коръән адәм баласына Кыямәт көнендә шәфәгатьче булырлар", - ди.) Ураза әйтер: "Әй Раббым, мин синең бәндәңне көндезләрен ризыктан тыйдым", - дияр. Коръән әйтер: "Йә Раббыбыз, мин бу бәндәңне төннәрен йокысыз калдырган идем, безнең шәфәгатебезне кабул итсәң икән", - диярләр. Раббыбыз әйтер: "Сезнең шәфәгатегез кабул булды", - дияр. Раббым безләргә дә бу икенең шәфәгатенә ирешергә насыйп итсә иде.

Рамазан аенда пәйгамбәребез янына көн саен Җәбраил фәрештә килә вә көн саен Рәсүлебезгә Коръән өйрәтә. Пәйгамбәребез (сгв) дә Рамазан аенда сәхабәләренең кайберләренә - өч көнгә бер мәртәбә, кайберләренә - җиде көнгә бер мәртәбә, кайберләренә ун көнгә бер мәртәбә Коръәнне укып чыгарга куша. Риваятьләрдә сурәтләнгәнчә, Җир йөзенең иң зур галимнәре - имам Әбу Хәнифә, имам Шәфигый Коръәнне Рамазан аенда алтмыш мәртәбә укып чыга торган булганнар. Бу исә - сәхабәләрнең Коръәнгә никадәр якын булуларын, ә безнең, кызганыч, нихәтле аннан ерак торуыбызны күрсәтә торган дәлил. Кадерле кардәшләрем, шуны да әйтергә кирәк: күләм артыннан куып кына, Коръәннең тирән мәгънәләренә төшенмичә, хаталы итеп укудан сакланырга кирәк. Ибн Габбас (рг) әйтә: "Минем өчен, ашыгып, бөтен Китапны укып чыкканчы, ашыкмыйча гына, һәр җөмләсенең мәгънәсенә төшенеп, бер сүрәне кат-кат укуым хәерлерәк", - ди. Раббым, безгә дә Коръән әһелләре булырга насыйп булса иде.

Рамазан аен сагынып, ел буе зарыгып көтсәң дә, санаулы көннәр бик тиз арада сизелмичә үтеп тә китә. Ай буе тоткан уразаң күңелне нечкәртә, укыган Коръәнең, гыйбрәтләндереп, иманны арттыра, укыган тәравих намазлары үзеңдә әхлакый сыйфатлар тәрбияләргә, сабыр булырга өйрәтә. Көтеп алган изге айның китәр вакытлары якынлаша барган саен, аның кадере тагын да арта башлый кебек. Изге Рамазан аеның ахыргы ун көне җитәр алдыннан, тел Раббысын зекер итеп, рәхмәтенә ирешермен дип, чын күңелдән ышанып, җан тынычлыгына ирешә башлыйсың. Рамазанның ахыргы ун көннәрендә якты өметләр тагы да арта башлый. Мин дә, Аллаһ теләсә, Раббымның рәхмәтенә ирешермен, Кыяматтә җәннәтенә керермен дип ышанган хәлдә, шатлыклы уйлар кичерә башлыйсың. Гайшә анабыз: "Рамазанның ахыргы ун төнендә пәйгамбәребез башка көннәргә караганда гыйбадәттә күбрәк тырышлык күрсәтә иде", - дип әйткән.

Хәсәнул Басри әйткәнчә, таң атканда, якты көн адәм баласына болай дип мөрәҗәгать итәдер ди: "Әй әдәм баласы, мин яңа көн, кичәге көн түгел, мине заяга үткәрмә, миннән мөмкин кадәр файдаланып кал. Мәгәр мин синең барлык кылган гамәлләреңнең Кыяматтә шаһиты булырмын. Иртәгәсе көнне инде яңа көн киләчәк һәм син мине Кыяматтән башка бүтән беркайчан да күрмәссең", - ди.


Пәйгамбәребез, Рамазан аеның ахыргы ун көне җитсә, төннәрен намазларда, гыйбадәтләрдә үткәрә, үзенең гаиләсен дә намазга, гыйбадәт кылырга дип, иртән иртүк уяткан. Ахыргы ун көнне, күбрәк мәчеттә булып, хатыннарыннан башка гыйбадәттә, тәүбәләрдә үткәрергә тырышкан.

***Алмаз хәзрәт ШӘРИФУЛЛИН,***
***Татарстанның көньяк төбәге казые,***
***Чистай районы имам-мөхтәсибе***

---

**Аксакал ГЫЙЛЬМУЛЛА хәзрәт:**

# "Безгә пикет-митинглар артыннан йөрергә кирәкми!"



**Башкалабызның Танкодром бистәсендә урнашкан Мәдинә мәчете күп кенә мәхәлләләргә үрнәк итеп куела. Күптән түгел генә әлеге мәчетнең имам-хатыйбы Гыйльмулла хәзрәт Хәлиуллин 80 яшьлек юбилеен билгеләп үтте. Ошбу мәчетнең имамы, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Аксакаллар шурасы әгъзасы Гыйльмулла хәзрәт соңгы вакытта республикада барган вакыйгаларга газетабыз аша үз мөнәсәбәтен белдерергә булды.**

***- Мәчетнең әйләнә-тирәсендә бик күп агачлар үсә, манарагыз ерактан күренми дә диярлек. Кайсы гына намазга килсәм дә, мәчет эче туп-тулы була. Кайдан табып киләләр диген мәчетегезне?***

- Әйе, бездән халыкның өзелгәне юк. Кайлардан гына килмиләр. Авылда Аллаһ йорты төзергә теләүчеләр безнең мәчетнең үлчәмнәрен алып китә. Кышлыкта Имамнарның белемен күтәрү курсларында укучылар безгә намазга йөрде, алар белән шактый тәҗрибә уртаклашырга өлгердек. Инде ничәмә-ничә ел әйләнәсе һәр җомга саен мәхәлләдәшләребезне кайнар пылау белән сыйлыйбыз. Рамазан ае саен һәркөн йөздән артык кешегә авыз ачу мәҗлесләре оештырабыз. Мәчет ишегалдын үзегез күреп торасыз.

***- Шулай да узган атнаның шимбәсендә яшьләр сезнең теңкәгезгә тигән дип ишеткән идек.***

- "Иртәгә пикет була" дигән өндәмәләр тотып, егетләр килеп керде. Мин аптырап калдым. Дөрес, дөнья булгач, безгә халыкның төрле сораулар белән килгәләгәне булды, ләкин мондый ук әдәпсезләр бар дип уйламаган идем. Басукырларда эш кайнаган вакытта кирәкмәгән эш белән йөреп, вакытларын әрәмгә уздырганнарын күреп, җәлләдем мин аларны. Мәчетнең ишегенә ябыштырып киткән белдерүләрен шундук юк иттем. Мәчет бит ул сәясәт белән шөгыльләнү урыны түгел, гыйбадәт кылу йорты. Намаз укучыларны борчып йөрүчеләргә карашым уңай булмаячак. Файдалы эш белән йөрүчеләргә ишек түрдән ачык. Без үскәндә: "Син нәрсә эшләргә телисең?" - дип сорап тормадылар, "Эшлә! Эшлә!" дип кенә әйттеләр. Хәзер нәрсә? Ваһһабчылык коткысына бирелгән яшьләр мәчеттә олыны - олы, кечене кече дип белми. Әгәр дә берәр кисәтү ясый башлыйсың икән, үзенә җайлы бер хәдисне өйрәнеп алган да, ак сакаллы бабайның бугазына ябышырга әзер, валлаһи...

***- Сезнең мондый күренешләргә юл куймау өчен башлап сүз әйткәнегез булдымы?***

- Мин имамнар җыелышында һәрдаим әйтеп килдем: "Җәмәгать, мәхәлләләребездә тәртип салыйк. Әби-бабаларыбыздан килгән юлыбыздан - имам Әбу Хәнифә мәзһәбе буенча барыйк!" - дип тәкърарладым. Колак салучылар булмады түгел, булды. Бу мәсьәләгә бармак аша карауның нәрсәгә илтәчәген мин биш-алты ел элек үк фаразладым. Диндәге үзара тарткалашулар аркасында Үзбәкстанда ниләр генә булып бетмәде. Үзебездә дә 1937 еллар җәберләүләре тиктомолдан гына килеп чыкмады. Ул вакытта имамнарның нәфесләре уйнау аркасында дин әһелләренең бер гөнаһсызлары да юк ителде. Күпне күргән кеше буларак шуны әйтә алам: безнең көннәрдә яшьләр оештыра торган пикет-митингларны туктатмасак, гөнаһлы кешеләр аркасында гөнаһсызлары да эзәрлекләнә башлаячак. Менә шушы мәсьәләдә халкыбыз уяу булырга, дөньяга күзен ачарга тиеш. Тарихыбызда булган олы фаҗигаләрне кабатламау ул бары тик үзебездән генә тора! Мондый пикетларга чакыручы кешеләр белән көрәшергә кирәк. Бүгенге урам җыеныннан иртәгә Гражданнар сугышы башланырга мөмкин. Мин үзем инде өченче мөфти белән тәртипле генә эшләп киләм. Минем җитәкчелегемдә җиденче мәчет төзелеп ята. Мине мөфтиләр гел куәтләп кенә торды. Ислам дине әхлакка нигезләнгән, без үзебезнең җитәкчеләребезгә итагать итәргә тиешбез. Илдус хәзрәт Фәизне алты йөз имам бертавыштан сайлап куйды. Шулай икән, дин башында торучыны санга сукмау дигән сүз түгелме соң бу? Моңа хөкүмәт тиз арада чаралар күрергә тиеш. Алайсам, бездә дә Кавказ сценарие кабатланырга мөмкин. Аек акыл белән фикерләү җитми безгә. Озын сүзнең кыскасы, тиз арада ыгы-зыгы оештыручыларны, фетнә чыгаручыларны тыярга кирәк. Бу безне яхшыга алып бармаячак. Кабатлап әйтәм: безгә пикет-митинглар артыннан йөрергә кирәкми! Алла сакласын, Чечня, Кавказ вакыйгалары безгә килә күрмәсен дип намаз саен дога кылам. Үзебезне-үзебез көлдереп йөрмик, милләтебезнең, республикабызның дәрәҗәсен саклап калыйк! Бигрәк тә 2013 елда Казанда узачак XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада алдыннан тынычлыкны сакларга кирәк. Тынычлыкны сайламыйбыз икән, ахыры хәерле булмас. Паникага бирелмик. Киләчәктә дә динебезне күтәрү өстендә эшләргә язсын!

***Нияз САБИРҖАНОВ сораштырды***

---

# ХАЛКЫБЫЗ – ДИНИ МӘГАРИФ

***XVIII гасырда Урта Иделдә классик Ислам мәгарифенең барлыкка килүе һәм үсеш алуы мөселман руханыйларын (дин башлыкларын) ике төркемгә бүлә: кадимчеләр (традиционалистлар) һәм җәдитчеләр (реформатор-модернистлар).***

Кадимчеләрнең төп катламын абыз даирәсеннән чыгучылар тәшкил итә. Алар нигездә авыл җирләрендә яшәүчеләрдән булалар, традицион карашлары белән аерылып торалар; Оренбург Диния назәрәте (ОМДС) төзелгәч, рәсми (официаль) дини җитәкчелек составына да керә башлыйлар. Җәдитчеләр үзләре күпчелек очракта кадимче мәдрәсәләрдә белем алалар. Шуңа да күренекле җәдитче Р.Фәхреддин "һәр милләтне һәлакәткә илтә торган" схоластика белән тулы Бохара мәгариф системасын тәнкыйть итә. Аның фикеренчә, Дагстан модселе схоластикадан азат булуы, хокукый һәм гуманитар аспектларга зур игътибар күрсәтүе белән аерылып тора.

Җәдитчелек феномены совет җәмәгатьчелеге фикерендә (шул исәптән Татарстан тарихчылары тарафыннан да) узган гасырның 70 нче елларына кадәр күп очракта "буржуаз-демократик реакция" феномены буларак каралды. Чынлап та, җәдитчелек тарафдарлары булып тамыр җәеп килүче татар буржуазиясе чыгыш ясаган, ләкин хәрәкәтнең алга таба сәясәтләшүе нигездә XVIII-XIX гасыр башындагы Россиядәге гомумсәяси "болганышлар" феномены белән бәйле. Шуңа да патша хөкүмәте җәдитчеләр эшчәнлегендә еш кына (һәм һич тә нигезсез түгел) пантөрки, панислами омтылышларны (төрки телләрдә сөйләшүче халыкларның, барыннан да бигрәк төрки-мөселманнарның бер милләт булып саналалар дигән шигарь астында Төркия хакимлегенә берләшергә тиеш булуы) күрә.

Җәдитчелек төшенчәсе кырым татарларының И.Гаспралы җитәкчелегендәге укыту формаларының берсе булган "җәдиди ысул" гыйбарәсенә барып тоташа. Беренче көннәреннән үк, җәдитчелек мөселман җәмгыятен камилләштерүне таләп итүче дини реформатор буларак тәкъдим ителә. Фундаменталь тенденцияләрнең киң таралыш алмавы Урта Иделгә хас мөһим үзенчәлек булып тора. Бу күпчелек очракта XX гасырга кадәр, әүвәл дини, аннан әкренлән дөньяви характер алган мәгариф системасының таралыш алуы аркасында мөмкин була. Моны без Урта Идел мәгариф системасына караган иске ысуллы (кадими) һәм яңа ысуллы (җәдиди) мәдрәсәләр мисалында күзәтә алабыз. Яңа ысулга әкренләп күчү XIX-XX гасыр башларында була. Кадими мәдрәсәләр нигездә дин тәгълиматы, мөселман хокукы белгечләре әзерләргә тиеш булалар. Кадими мәдрәсәләрдә формаль уку баскычлары булмый, белем баскычлары буенча күтәрелү XV-XVI гасырларда язылган (гомум кабул ителгән) китаплар белән танышу, аларны өйрәнү белән билгеләнә. Төп уку предметы - дин тәгълиматы, ә гомуми белем бирү предметлары ярдәмче характерда була: гарәп теле Коръән һәм дини йолаларны башкару теле буларак, мантыйк (логика) һәм фәлсәфә (философия) дин гыйлемен формаль-логик дәлилләү өчен өйрәнелә. Шуңа да традицион предметларга басым ясала: сарыф һәм нәхү (гарәп теленең морфологиясе һәм синтаксисы), мантыйк (логика), хикмәт (фәлсәфә), гакыйдә яки каләм (догматика), фикъһе (мөселман хокукы) һ. б. Дөньяви характер фараиз (мирас бүлү кагыйдәләре) һәм шәмсия (исәп-хисап), исагога (Аристотель тәгълиматына нигезләнгән мантыйк) өйрәнүдә күренә, шулай ук арифметика, никах буенча мәгълүматлар, хифзысихәт (гигиена) һ. б. предметлар өйрәнелә. Аннан тыш, китапханәләрнең бай булуы тырыш шәкертләргә (мәдрәсәдә белем алучыларга) гарәп әдәбияты, тарих, география һ. б. фәннәр белән танышырга да мөмкинлек бирә.

Күп кенә кадими мәдрәсә шәкертләре Аристотель, әл-Фәраби, Әбугалисина, әл-Бируни, Низами, Нәваи һәм башкаларның карашлары белән танышу мөмкинлегенә ия була. XIX

# РИУ ректоры: "Татарстанда яшерен радикаль агымнар юк"

**Россия ислам университеты ректоры Рәфыйк Мөхәммәтшин "Slon.ru" интернет-басмасы хәбәрчесе белән әңгәмәдә республикабызда мөселманнар белән бернинди дә низаг булмавын раслый. "Әйе, Татарстанда төрле агымнар бар, әмма традицион Исламга каршы оешкан идеологик агым юк", - ди ул.**

***- Татарстанда дини агымнар арасында конфликт никадәр дәрәҗәдә көчле?***

- Сизелерлек бернинди дә каршылык (конфликт) юк. Төньяк Кавказдан аермалы буларак, төрле агымнар арасындагы чик монда алай ук күзгә чалынмый. Әйе, Татарстанда төрле агымнар бар, әмма алар нинди дә булса оешкан төркемнәр кебек түгел. Бу - аерым шәхесләр, алар үзләренең карашларын ярыйсы гына җиткерәләр. Республикабызда традицион Исламга каршы оешкан идеологик агым юк.

***- Сез ваһһаби оешмаларны күз уңында тотасызмы?***

- Әйе. Узган гасырның туксанынчы елларында, ислам дине халкыбызга кабаттан кайта башлагач, бирегә чит ил мөселман оешмалары хисабына көн күрүче мөгаллимнәр килде, алар мәдрәсәләр ачты. Без гел әйтә киләбез, Россиядә традицион Ислам меңьеллык тарихка ия, дибез. Әмма совет чорында мөселман руханыйларыннан мәчеттә утыручы бабайлар гына бар иде. Алар бүгенге көндә дә бар һәм алар яшьләр өчен ниндидер бер гореф-гадәт һәм йолалар җыелмасын гәүдәләндерәләр. Аннан соң тагын да көчлерәк йогынты гарәп телен яхшы белүче хәзерге вәгыйзьләрдән (вәгазь сөйләүчеләр) килеп чыкты. Һәм шуңа күрә җәмгыятьтә буш хыял (иллюзия) барлыкка килә, ә чын Ислам - пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) ватанындагы кебек дигәнрәк. Әмма бу радикаль агымнар формалаштыруга ук алып килеп җиткерми, бары тик басым ясаулар даими рәвештә традицион булмаган кыйммәтләр юнәлеше белән кушылды. Хәлләр тагын шуның белән дә катлауланды ки, берничә агым идеологик яктан берләште. Намазны алар хәнәфи мәзһәбе буенча



укыйлар, ә идеологик яктан сәләфилеккә ябышып яталар. Төньяк Кавказда очрый торган тулы канлы сәләфиләрне татарлар арасында табуы кыен. "Сездә ваһһабилар кайда?" - дип сорыйлар икән, мин югалып калам, нәрсә дип җавап бирергә белмим. Бу бары тик безнең республиканың гына түгел, ә үзәк Россиянең дә феномены.

***- Дини нигезгә корылган яңа терактлар булыр дип шөбһәләнергә урын бармы?***

- Мин чын (реаль) нигез юктыр дип уйламыйм. Барысы да күптән түгел булган теракттан соңгы шикләнүдә. Без җәмгыятьнең радикальләшүе турында сөйлибез икән - бу бары тик идеология генә түгел, бу шулай ук икътисади проблемалар да, һәм хәл ителмәгән социаль мәсьәләләр дә. Ә без беләбез, Татарстан - ул иң хәвеф-хәтәрсез төбәкләрнең берсе, ягъни радикальләшү өчен социаль-сәяси яшерен сәбәпләр юк. Һәм идеологик серләр дә юк - Татарстан аеруча толерант төбәкләрнең берсе булып тора, монда беркайчан да конфессияләр арасында каршылыклар булмады. Һәм мин аерым бер вакыйга радикальләшү өчен этәргеч булыр, дип уйламыйм.

***- Ә теракттан соң Казанда аеруча нинди юрамалар популяр?***

- Юрамалар икәү: идеологик һәм икътисади - һәм, күрәсең, шуның икесе дә яхшы итеп өйрәнелә. Вәлиулла Якуповны үтерүдә икътисади яшерен сәбәп булгандыр дип сөйләве кыенрак - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә ул бизнес-проектлар белән шөгыльләнмәде. Һәм, әгәр дә бу ялган "эз" булмаса, бары тик идеологик сәбәпләр генә кала. Ул, дөрестән дә, традицион кыйммәтләр күзлегеннән радикаль позиция биләде, берничә мәртәбә әлеге мәсьәлә буенча каты итеп әйткәләгән иде. Россиядә ваһһабчылыкны тыючы закон булырга тиеш дигән сүз аның авызыннан чыкты. 2010 елда ул массакүләм мәгълүмат чараларында ниндидер бер ваһһаби холдинг барлыкка килү эшендә административ һәм дини структураларның берләшүен дә белдерде. Вәлиулла хәзрәт ваһһабчыларга, кызганычка каршы, шактый югары структуралар, шул исәптән көч структуралары да ярдәм итә дип ачыктан-ачык әйткән иде. В.Якупов - традицион Ислам әдәбияты буенча бик күп китаплар бастырган "Иман" нәшриятының җитәкчесе. Россиядә бүтән мондый нәшрият юк. Аннан китапларны илебезнең барлык үзәк мәчетләре күпләп сатып алды. Шул хакта мөфти турында да әйтергә мөмкин - ул сайлангач, аның тарафыннан шактый кыю фикерләр әйтелде. Ул кадрларга кагылышлы мәсьәләләрне хәл итте, идеологик сәбәп өскә калыкты, һәм бу төрле дини структураларда эшләүче рәсми кешеләр тарафыннан канәгатьсезлек уятты.

***- Теракт кем тарафыннандыр читтән оештырылган дигән юрама бар.***

- Башка илләр тарафыннан - билгеле инде юк. Дөрес, соңгы вакытта "Кавказ-центр" Урта Идел буена игътибар итәргә, шуның белән шөгыльләнүче махсус структура төзергә кирәк, дип яза башлады. Әмма нинди дә булса Кавказ "эз"е Татарстанда сизелерлек булмады. Вуз укытучылары һәм чит ил миссионерлары бездә инде юк диярлек. Бары тик гарәп илләрендә туып үсеп, безгә күчеп килгәннәр - Россия гражданлыгы алып монда эшләүчеләр генә калды.

---

# КАПКА ТӨБЕНДӘ

(бәян-вәгазь)

**Бүген тагын бик эссе булды. Күләгәдә - 40 градус! Җәйге челләдә кызган һавадан хәлсезләнеп беткән агачлар һәм басудагы игеннәр яңгыр көтеп ялвара сыман: "Их, бер рәхәтләндереп явып китсә икән! Кайда йөрисез сез, болыт-туганнар?!."**

Иртәдән бирле болында барлы-юклы үләнне чемченеп йөргән көтү, әлсерәп бетеп, авылга кайтып керә. Хуҗалары үз малларын якын гаилә әгъзасы кебек каршы алып, көндәлек кичке эшкә тотына. Тагын бер көн ахырына якыная.

Кояш сүлпәнәя төшкән нурлары белән: "Болай булса да кыздырып калыйм әле!" - дигән шикелле көнбатышка килеп җиткәндә, Гарәфетдин бабай, гадәттә, капка төбенә чыгып утыра. Җәйге явымсыз көннәрдә ул шулай иске, ярылып беткән эскәмиядә кояшны озатып, ахшамны каршы ала. Бабайның яше инде җитмеш биштән узган булса да, ул әле шактый аңлы, акыллы, төпле фикерле. Авылдашлары аны хәтта "хикмәт сандыгы" дип тә атыйлар, чөнки нәрсә генә сөйләсә дә, нинди сораугa җавап бирсә дә, "шулай - болай ул" дип кенә калмыйча, тормыштан берәр мисал китереп, дини белемнәрен дә эшкә җигеп, әйтәсе фикер-сүзләрен бик хикмәтле, гыйбрәтле, уйландырырлык итеп җиткерә белә ул. Дөрес, карчыгы Бибинур түти генә аны: "Шул эскәмиясенә чыгып утыра да, ләчтит сатып кояш баета!", - дип сүгә. Бабайның моңа исе китми, түбәтәен төзәтеп куя да: "Кояшны мин түгел, Аллаһ баета", - дип мыек астыннан хәйләкәр елмаеп, тыныч кына җавап бирә.

Әллә Гарафетдин абыйның нурлы йөзе үзенә тарткангамы, күрше-тирәдә яшәүче авылдашлары бабай янына җыела, арада хатын-кыз заты булса, Бибинур түти дә түзми - карты янына чыгып утыра. Бүген әнә югары очта яшәүче кодагыйлары Мәрфуга да бирeдә икән.

- Үтеп барышлый гына туктадым, үтеп барышлый гына! - дип акланган карчыкка дикъкать бирмичә, Бибинур апа усал вә рәхимсез итеп күзлеген ялтыратып, башын читкә бора. Яратмый ул аны. Шуңа ишетәсе дә, күрәсе дә килми. Аларның бер-берсе белән килешә алмавының сәбәбе - үзе бер тарих, бер гыйбрәтле кыйсса. Әмма кызы Миңсылу Мәрфуганың малаена кияүгә чыкканнан соң, карчыкларның үзара мөнәсәбәтендәге ярык тагын да зурайды, элекке киеренкелек тагын да артты. Горур табигатьле Бибинурның кодагыеның хәтта нәзек тавышыннан да саруы кайный. Шәйтан суы белән дус булган кияүнең кызын, оныкларын интектереп яшәтүе исә Мәрфуга карчыкка карата начар мөнәсәбәтнең көчәюенә тагын бер сәбәп булды.

- Кодагы-ый! Төнәген күчтәнәч итеп биргән балыгыз бигрәкләр дә тәмле булган! - дип, ялтыраган күзлеккә күпер салырга ниятләп, тәмле-татлы итеп сайрый башлый Мәрфуга. - Юкә балымы ул, әллә чәчәкнекеме?

- Белмим! - дип, нечкә иреннәрен кысып, кырт кисә Бибинур. - Без бал кортлары артыннан очып йөрмәдек!

Бибинур түти үзенә әйтмичә кодаларга бал биргәне өчен картын ничек сүгәчәген планлаштырып утырган арада Мәрфуга әби Казаннан бабасы янына кайткан студент оныгы Айдарга сүз катарга була:

- Кәк дилишкә? Ә-ә?

Капкага сөялеп торган озын буйлы Айдар болай да тәбәнәгрәк булган, әле җитмәсә бераз бөкрәйгән карчыкка өстән аска күз ташлап:

- Әлхәмдүлилләһи, Ходай биргәненә шөкер! - дип ипле генә җавап кайтара.

"Татарча юньләп белми бугай бу", - дип уйлап, Ай-



дарга русчалатып дәшкән карчык шәһәр егетенең шулай төпле, дин әһелләредәй җавап бирүенә башта аптырап китә, соңыннан исә: "Гарәфетдин үз оныгын өйрәтмичә калмас шул!" - дигән нәтиҗәгә килә. Ә бал турындагы соравына Бибинурның тупас итеп җавап бирүе йөрәгенә ярамаганга, ул, кодагыен төрттереп алырга теләп, әче тавыш белән сорый:

- Айдар улым, ял итәргәме, әллә былтыргыча ат урынына эшләргәме килүең?

**(Дәвамы газетабызның киләсе саннарында.)**

***Ришат КУРАМШИН,***
***Кукмара мәдрәсәсе мөдире***

---

# ТАРИХЫНДА

гасыр дәвамында татар мәктәпләрен үзгәртеп кору һәм аңа дөньяви характер бирү буенча күп санлы (татар тарихчыларының исәбе буенча сигезгә якын) проектлар эшләнелә. Ул авторлар арасында В.Радлов, Ш.Мәрҗани, Р.Фәхреддинов һ. б. бар. Мәсәлән, Р.Фәхреддинов берсендә дини, икенчесендә дөньяви предметлар укытыла торган ике бүлекле уку йортлары төзү проектын тәкъдим итә. Ләкин патша хөкүмәте бу проектларда пантөрки һәм панислами омтылышлар күрә. Мисал өчен, 1910 елны Эчке эшләр министры П.Столыпин чакыруы буенча үткән "Махсус киңәшмә"дә мәктәп һәм мәдрәсәләрдән гомуми характердагы предметларны, шул исәптән рус телен дә өйрәнүне алып ташларга һәм программада бары тик дини гыйлемнәр өйрәнүне генә калдырырга дигән карар чыгарыла.

Ләкин яңа ысуллы татар мәктәбе кызу темплар белән үсә бара. Төп җәдит мәдрәсәләре, билгеле булганча, авыл җирләрендә булган кадими мәдрәсәләрдән аермалы буларак, шәһәрләшкән тирәлектә урнаша. "Мөхәммәдия" һәм "Касыймия" (Казан), "Рәсүлия" (Троицк), "Иж-Бубый" (Нократ губернасының Сарапул өязе) мәдрәсәләре - аеруча күренекләләрдән санала. Төп предметлар булып элек-электән килгән дини дисциплиналар калса да, аларда урта мәктәпнең гомуми белем бирү фәннәре дә өйрәнелә. Мәсәлән, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә XX гасыр башында ук рус теле, арифметика, матур язу, хисап, география, физика, геометрия, Россия тарихы, гомуми тарих, төрки халыклар тарихы, этика, гигиена, юриспруденция, психология, логика, философия, педагогика һәм башка фәннәр укытыла. Шул ук вакытта башлангыч сыйныфлардан урта сыйныфларга күчә барган саен дөньяви предметларның саны арта бара (1913 елны мәдрәсәдә 14 еллык курс булган).

Эчтәлеге, белем бирү дәрәҗәсе, дини һәм дөньяви компонентларга туры килгән өлеш чагыштырмасы буенча башка алдынгы җәдит мәдрәсәләре дә ("Иж-Бубый", "Хөсәения", "Галия") үзенчәлекле була. Татар мәктәпләрендә 1911-1913 елларда өйрәнелгән дәреслекләрне карап тикшергән цензура комитетының "Дәреслекләргә күзәтү"ендә 394 дәреслеккә анализ ясалган, аларның 70 проценты дөньяви фәннәргә туры килә.

1910 елга туксан процент мәктәп һәм мәдрәсәләр аваз (җәдит) ысулына күчеп бетәләр. 1905 елга бер Казан губернасында гына да 34860 егет һәм 15599 кыз бала укыган 845 мәдрәсә исәпләнелә. 1907 елга уку йортлары саны сигез йөз җитмеш җидегә (66787 белем алучы), ә 1913 елга тугыз йөз алтмыш җидегә (79496 белем алучы) кадәр арта. Болардан тыш, берләштерелгән рус-татар уку йортлары да киң таралыш ала. 1905 елга Казан губернасында татар балалары өчен русча укытыла торган 11 шәһәр, 8 авыл мәктәбе була. 1914 елга губернада Мәгариф министрлыгы карамагындагы рус-татар көллиятләренең һәм рус сыйныфларының саны алтмыш тугызга җитә. Акрынлап хатын-кызларга белем бирү дә зур үсеш ала. 1890 елны беренче җәдит татар хатын-кыз мәктәбе ачыла.

Зур үсешкә ирешкән мәгариф системасы татар халкында укымышлылык дәрәҗәсенең югары булуына нык ярдәм итә. Бу турыда Россия чиновникларының хисап кенәгәләрендә дә язылган, аларның күпчелеге татар кешеләренең "барысы да укый-яза белә" дип билгеләп үтә. Кайбер тикшерүчеләр тарафыннан татарлар арасындагы укымышлылык (укый-яза белү дәрәҗәсе) 80 % дип бәяләнә, ләкин бу сан "үзенчә" укымышлылыкны аңлата, ягъни гарәп графикасы нигезендә укый-яза белү, дини гыйлем нигезләрен белү. 1905 елгы земство статистикасы буенча, татарлар арасында укымышлылык 20 процентка якын булган, ә рус телен су кебек эчү - 4 %. Татар тарихчыларының бу саннарга шик-шөбһә белән карауларына да карамастан, руслар арасында укымышлылык 25 % булып теркәлгән, ягъни татарлар белән руслар арасында укымышлылык дәрәҗәсе нибары биш процентка гына аерылып торган.

**Марат хәзрәт МӘРДАНШИН,**
**тарих фәннәре кандидаты,**
**Татарстанның көньяк-көнчыгыш төбәге казые**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Сәхәр тәмамлана | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 28.07.12 | 2:41 | 3:11 | 4:41 | 13:02 | 18:19 | 20:57 | 22:27 |
| Якшәмбе | 29.07.12 | 2:43 | 3:13 | 4:43 | 13:02 | 18:17 | 20:55 | 22:25 |
| Дүшәмбе | 30.07.12 | 2:45 | 3:15 | 4:45 | 13:02 | 18:16 | 20:53 | 22:23 |
| Сишәмбе | 31.07.12 | 2:47 | 3:17 | 4:47 | 13:02 | 18:15 | 20:51 | 22:21 |
| Чәршәмбе | 1.08.12 | 2:49 | 3:19 | 4:49 | 13:02 | 18:13 | 20:49 | 22:19 |
| Пәнҗешәмбе | 2.08.12 | 2:51 | 3:21 | 4:51 | 13:02 | 18:12 | 20:47 | 22:17 |
| Җомга | 3.08.12 | 2:53 | 3:23 | 4:53 | 13:02 | 18:11 | 20:45 | 22:15 |
| Шимбә | 4.08.12 | 2:55 | 3:25 | 4:55 | 13:02 | 18:09 | 20:43 | 22:13 |




# РАМАЗАН АЕ: АЛАБУГА

**Казанда булып үткән фаҗигале вакыйгалар мөселманнарны борчуга салса да, Рамазан аен алар шатланып каршы алды.**

Алабуга шәһәренең Җәмигъ мәчете имам-хатыйбы Азат хәзрәт Шәрипов җомга вәгазендә мөселманнарны түзем һәм сабыр булырга өндәде: "Бу - өммәтебез өчен сынау; без бу авыр заманда бердәм булырга һәм Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәп, игелекләр кылырга тиешбез".

Мөэмин-мөселманнар ураза тотуга бик җаваплы карыйлар. Намаз укый белмәүчеләр арасында да уразага керүчеләр бар. Шуңа күрә мәчетләрдә халык башка айлардан күбрәк - фарыз намазларга киләләр һәм тәравих намазларын калдырмаска тырышалар. Быел Алабуганың үзәк мәчетендә тәравих намазларын Габделвәли хәзрәт, Ислам хәзрәт, Вадим хәзрәт һәм Азат хәзрәт алып бара. Тәравих намазларына йөз иллеләп кеше йөри.

Мөселманнар Рамазан аенда күбрәк игелек кылырга тырышалар, ифтарларны үткәрүдә катнашалар, мәчетләрне төзекләндерергә булышалар. Җәмигъ мәчеттә һәркөнне йөзләп кешегә ифтар ашы үткәрелә, монда ирләр, хатын-кызлар һәм балалар да килә. Ифтарларны күбесенчә мәчеткә йөрүчеләр оештыра.

Алабуга шәһәрендә бүгенге көндә өч мәчет эшли. Җәмигъ мәчеттән кала ифтарлар Әл-Кадыйр мәчетендә дә оештырыла. Монда иң зур ифтар мәчет янәшәсендәге кафеда 20 июль көнне уздырылды. Нур мәчете дә игелекле эшләрдән калышмаска тырыша - анда да берничә ифтар уздырылды.

Җәмигъ мәчеттә оештырылган ифтар выкытында берничә кеше белән әңгәмә кордык.

**Айнур ФАЗЛЫЕВ, 23 яшь, машина йөртүче булып эшли:**

- Кайчан намаз укый башладыгыз?

- 2011 елда. Август аенда төштә үлгәнемне күрдем, тормыш турында уйлана башладым һәм намазга бастым. Ә уразаны күптәннән тотам инде мин.

- Ураза тотарга кыен түгелме?

- Юк. Үземне яхшы хис итәм, сәхәргә тормаганда гына кыенрак.

- Ураза сиңа нәрсә бирә?

- Мин рухи көч алам, нәрсәдер әйтер алдыннан яхшылап уйлыйм, сабыррак һәм тотнаклырак булырга өйрәнәм.

- Ифтарга кая йөрисең?

- Быел көн саен диярлек Җәмигъ мәчеткә киләм.

- Ифтарлар турында ни әйтерсең?

- Быел үткән елдагыга караганда күпкә яхшырак оештырылган, урыны да уңайлырак.

- Син өйләнгәнме?

- Быел өйләнергә җыенам.

- Сиңа гаилә бәхете телибез, киләсе очрашуда синең белән гаилә башлыгы һәм әти кеше буларак әңгәмә корырбыз дип өметләнәм.

**Марзия ШАКИРОВА, 62 яшь, пенсиядә:**

- Кайчан намаз укый һәм ураза тота башладыгыз?

- Күптән, узган гасырның 80 нче елларында ук намаз укый һәм ураза тота башладым.

- Ураза тотарга кыен түгелме?

- Бернинди кыенлыгы юк, киресенчә, үземне бик яхшы хис итәм, Аллаһы Тәгалә миңа көч-куәт бирә, бу үзенә күрә бер могҗиза. Ашыйсы да килми. Рамазан ае үзенең бәрәкәте белән башка айлардан аерылып тора. Рамазан аеның һавасы да искиткеч хуш исле, гади су һәм ризык та бик тәмле.

- Ифтарлар турында да берничә сүз әйтеп үтсәгез иде.

- Ахшамның азанын күңел күтәренкелеге белән тыңлыйм. Ифтарга бик күп кеше килә, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте киң - өстәлләр ризык белән тулы. Ләкин шул ук вакытта ачлыктан интегүче кешеләр турында да онытмаска кирәк.

- Киләчәккә планнарыгыз нинди?

- Аллаһы Тәгаләдән мине мәчеттән, намаздан, уразадан аермавын үтенәм. Быел хаҗ кылырга җыенам.

- Аллаһы Тәгалә догаларыгызны кабул итсен, теләкләрегез тормышка ашсын.

**Репортаж Алабуга мөхтәсибәте белән берлектә әзерләнде**





## Йөрәк авырулы кешеләргә ураза тотарга ярый

**Төркия университеты профессоры, доктор Рамазан Акдемир йөрәк авырулары булган кешеләр өчен уразаның файдасы турында әйткән, дип хәбәр итә www.islam-today.ru сайты.**

Клиник тикшеренүләр күрсәткәнчә, ураза тоту йөрәк өчен һәм, гомумән, кеше сәламәтлеге өчен бик тә файдалы. Организм табигый юл белән шлак һәм токсиннардан арына. Профессор сүзләренә караганда, ураза йөрәк өянәге килеп чыгуга түгел, ә киресенчә, аның кимүенә китерә. Акдемир шулай ук, ураза тотучыларның бәхетлерәк, рухи яктан баерак хис итүләрен билгеләп үтә, ә күңел күтәренкелеге, үз чиратында, һәркемнең физик хәлен яхшыртырга булыша.

Билгеле булганча, дәвалануда мөһим рольне авыруның рухи халәте уйный. Шул ук вакытта доктор йөрәк авырулы кешеләргә сәхәр һәм ифтарда күбрәк сыеклык эчәргә, артык эсседән сакланырга һәм төнлә табиблар биргән даруларны эчәргә кирәклеген ассызыклый. Шулай ук ул яңа гына операция кичергән, авыр стадиядәге, даими рәвештә дару кулланучы, урын өстендә ятучы авыруларга ураза тотарга ярамаганлыгын әйтә.

Профессор Рамазан Акдемир йөрәк авырулы кешеләргә генә түгел, барлык мөселманнарга да үзенең киңәшләрен җиткерә: "Ураза тотарга теләгән кешеләр кыздырылган, майлы ризыкларны ашамаска тиеш. Күбрәк сусыл продуктлар һәм җиләк-җимеш ашарга кирәк. Ураза вакытында ашау-эчүдән тыелып торганлыктан, кеше организмы бик күп сыеклык югалта. Шунысы да мәгълүм булсын: ифтар вакытында бик тиз ашый башларга киңәш ителми".


## Түбән Кама шәһәре "РИСАЛӘ" мөселман мәдрәсәсе
### *2012-2013 нче уку елына УКЫРГА ЧАКЫРА*

***Мәдрәсә IX яки XI сыйныфны тәмамлаган егетләрне кабул итә һәм имам-хатыйблар, башлангыч дини белем, гарәп теле укытучылары әзерли.***

**Уку вакыты - 3 ел.**

Укучылар өчен түбәндәге шартлар тудырылган:
1. Тулай торак (бушлай).
2. Дәреслекләр белән тәэмин итү.
3. Көненә өч тапкыр ашату (бушлай).

**Укырга керү өчен түбәндәге документлар таләп ителә:**
1. Директор исеменә гариза.
2. Паспорт.
3. Хәрби комиссариатта теркәлү турында таныклык яки хәрби билет.
4. 4х3 зурлыгындагы 4 фото.
5. Медицина белешмәсе (86-ф).
6. Укыган уку йортларының таныклыгы (аттестат яки диплом) һәм характеристика.

**Укулар 1 сентябрьдән башлана.**

Белешмәләр өчен телефоннар: 89179252131, 89872290431.

Адрес: 423570 Түбән Кама шәһәре, Химиклар проспекты, 59 нчы йорт, Үзәк мәчет.


## Ифтарларга рәхим итегез, казанлылар!

**Рамазан ае дәвамында Казан мөхтәсибәтенең Мәрҗани мәчете каршында көн саен өч йөз кешегә ифтар ашы оештырыла.**

Башкалабызда бу рәвешле авыз ачуны беренчеләрдән булып Казан шәһәре имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов башлап җибәргән. Мондый чатыр Казанда бердәнбер. Быел инде бишенче ел рәттән биредә ураза тотучылар авыз ача. Бу чараны оештыруны мәчет һәм иганәчеләр үз өстенә ала. Күренекле имамнарыбыз тарафыннан вәгазь сөйләнелә, Коръән укыла. "Ярдәм итәргә теләүчеләр булса, Рамазан аенда үз өлешләрен кертә алалар", - диде Казан шәһәре имам-мөхтәсибенең беренче урынбасары, Мәрҗани мәчете имамы Илфар хәзрәт Хәсәнов.

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 5 (148) чыгарылыш.
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9410.
**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 2 август көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**